РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның «02» август № 58

«Кукмара муниципаль районының Кукмара ш.т.б. муниципаль берәмлеген су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны чыгару схемасын раслау турында» 2015 елның 22 апрелендәге 13 номерлы Кукмара поселогы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны чыгару турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Үзәкләштерелгән юынтык суларны чыгару (канализация) системасын җирлекләрнең яисә шәһәр округларының үзәкләштерелгән юынтык суларны чыгару системаларына кертү турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 05 сентябрендәге 782 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 31 маендагы 691 номерлы карары, «Су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны чыгару схемалары турында» 782 номерлы карары нигезендә карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Кукмара поселок башкарма комитетының 2015 елның 22 апрелендәге 13 номерлы карары белән расланган 2015 елдан алып 2030 елга кадәрге чорга су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу схемасына «1.1. бүлеген өстәргә Үзәкләштерелгән юынтык суларны чыгару (канализация) системасын җирлекләрнең яисә шәһәр округларының үзәкләштерелгән юынтык суларны чыгару системаларына кертү турында белешмәләр», аның эчтәлеге түбәндәгечә:

«1.1. Үзәкләштерелгән юынтык суларны чыгару (канализация) системасын җирлекләрнең яисә шәһәр округларының үзәкләштерелгән юынтык суларны чыгару системаларына кертү турында белешмәләр.

Кукмара шәһәренең үзәкләштерелгән юынтык суларны чыгару системасына карата Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 31 маендагы 691 номерлы карары белән расланган үзәкләштерелгән юынтык суларны чыгару (канализация) системаларын җирлекләрнең яисә шәһәр округларының үзәкләштерелгән юынтык суларны чыгару системаларына кертү Кагыйдәләрендә билгеләнгән үзәкләштерелгән юынтык суларны чыгару (канализация) системасын җирлекләрнең яисә шәһәр округларының үзәкләштерелгән юынтык суларны чыгару системаларына кертү критерийларының җыелмасын үтәү тәэмин ителә.

Шуңа бәйле рәвештә, Кукмара шәһәренең үзәкләштерелгән юынтык суларны чыгару (канализация) системасы җирлекләрнең һәм шәһәр округларының үзәкләштерелгән юынтык суларны чыгару системаларына керә».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р. Р. Хәйруллинга йөкләргә.

Җитәкче Р. Ф. Нотфуллин